**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлегенең Кече Боерган авылында гражданнар җыены карары**

20.11.2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлегенең Кече Боерган авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Күшке авыл җирлегенең Кече Боерган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабуга (Кече Боерган авылында ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм Кече Боерган авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлауга;

- Кече Боерган торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Күшке авыл җирлегенең Кече Боерган авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Күшке авыл җирлеге башлыгы _________ А.В. Стрелков

Халык җыены секретаре _________ Л.Г. Мусина